Sabira Stahlberg

# Filip hayvan bakçasında



aybagar

**Sabira Stahlberg**

# Filip hayvan bakçasında

**Fazile Nasretdin tärcemäse**
**Maria Viitasalo räsemnäre**

Helsinki 2022

*Tampere tatar cämiyätenä (Tampereen tataariseurakunta, per. 1943), Finlandiya İslam Cemaatinä (Suomen Islam-seurakunta, per. 1925) häm Oskar Öflund vakıfına matdi yärdämnäre öçen samimi rahmätlärebez.*

**Ciñel tel däräcäläre**
**Däräcä 1: İñ ciñel**
Däräcä 2: Ciñelräk
Däräcä 3: Ciñel

Tatar, 2. basma / edition

Şved telendä / Original: *Filip i djurparken*
Tärcemä: Fazile Nasretdin
Eş törkeme: Albina Samarhan,
Kamer Yafay Nogmanov, Liliä Däülät

© Sabira Stahlberg 2022
© Fazile Nasretdin, tärcemä / translation 2022
© Maria Viitasalo, räsemnär / illustrations 2022

Bokpil ▸ bokpil.eu
Aybagar ▸ aybagar.eu
Helsinki 2022

ISBN 978-952-7334-36-2 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-37-9 (E-kitap, PDF)

# Bülem 1

Minem isemem Filip.
Min akulalarnı yaratam.
Akulalar dönya kadär zur häm kurkınıç.
Alarnıñ teşläre küp.
Arkalarında ber ütken kanat bar.
Minemçä, akulalar şäp.

Min ütken teşle hayvannarnı yaratam.
Küpme kurkınıçrak bulsa,
tagın da kübräk yaratam.

Bez – äti, äni häm min ber
zur akvariumga bargan idek.
Akvariumda diñgez
balıklarınıñ küp törläre bar.
Anda törle diñgez hayvannarı da yäşi.

Yaña kameram belän bik küp
fotoräsemnär töşergän idem.
Äle komputerımda bik
kurkınıç akulalarnıñ şäp räsemnäre bar.
İñ yaratkannarım yulbarıs akulaları.

Bibinur apam häm Sofia kuzinım
äle bezdä kunakta.

Sofianıñ mäktäbendä yallar
häm apa eşennän yal könnäre algan.
Alar başka şähärdä toralar.
Cäyen bezgä kunakka kilgälilär.
İke atna toralar. İke atna!
Niçek çıdarga!

Bibinur apaga çıdıy almıym,
şunıñ öçen aña apa gına dip endäşäm dä.
Ul berkayçan da kızık
närsälär eşlärgä rohsät itmi.

Minem äniyem dä
vakıtı-vakıtı belän açulı häm nervalı.
Läkin ul apa kebek ük açuımnı kitermi.
Agaçka mengändä, äni kıçkıra:
– Filip, saklan!
Läkin apa:
– Filip, şunnan uk töş.
Huştan kitäm!
Bu nindi ahmaklık.

Bibinur apa bik ahmak keşe.
Anıñ ete tagın da ahmagrak.
Etneñ iseme Bikbay.
Ul keçerük kenä pudel,
iseme üzennän ozınrak.

Bikbayga Bili dip endäşälär,
läkin min Cili dip isem birdem.
Çönki anıñ kolakları yögergändä cilferdi.

Apam Ciline bäbäy kebek karıy.
Anı häryakka alıp bara.
Törle tatlılar aşata.
Uylap karaçı, ägär dä Cili
taza bulsa ide,
dürtayaklı yonlı kazıga
ohşar ide.

Kuzinım Sofia böten
närsäne belä.
Sofiaga da çıdıy almıym.
Ul mine nadan dip uylıy.
Läkin äni dä,
äti dä anı bik yaratalar.

Äni äytä:
– Sofia bik söykemle.
Ädäple dä, tıñlauçan da.
Äti äytä:
– Sofia akıllı.
Filip, siña añardan ürnäk alırga kiräk.
– Yuk rahmät, cavap biräm.
– Ul täkäbber. Min kılançık
keşelärne yaratmıym.

# Bülem 2

Sofia turındagı fikerlärem belän
äti-änine ışandıra almadım.
Kiresençä. Äni äytä:
– Sofia sälätle kız.
Kitaplar ukıy häm dä bik batır.

Äti östi:
– Filip, siña kübräk ukırga kiräk.
Dävamlı ukıp torsañ, ziheneñ arta.
– Yuk rahmät, cavap biräm.
– Ay monnan karaganda niçek yırakta,
anı Sofia belä, şik tä yuk.
Läkin min ayga barırga uylamıym.
Min akulalarnı kulga iyäläşterergä telim.

– Akulalar yırtkıç hayvannar.
Sine aşap kuyarlar, äni äytä.
– Menä şunıñ öçen.
Alar keşene dulkınlandıralar.
Mine aşamıylar.
Min alarnı yaratam.
Anı alar belälär, cavap biräm.
Äti belän äni, ikese dä
avır sulap başların çaykıylar.
– Berkönne Filipkä akıl kerer inde, äni äytä.

– Şulay bulsın inde, äti östäp kuya.
Bügen min apa häm Sofia belän
hayvan bakçasına barırga tiyeş.
Äti belän äni ikese dä eştä.
Äni äytä, Sofia hayvan bakçasın
kürergä teli dip.
Sofia bik hayvannar yarata.
Alar turında haman söyläp tora:
– Beldegezme, agaç bakası
agaçka menälä, dip añlata.
– Tämam Filip kebek.
Sofia miña mıskıllap karıy.
Min açulanam.

– Min zooparkka barırga uylamadım, äytäm.
– Anda küñelle, äni äytä.
– Sin ürmäküçlär yaratasıñ bit.
– Kurkınıç hayvannarnı räsemgä
töşerä alasıñ, äti äytä.
– Kamerañnı onıtma, iskärtä.

Minemçä hayvan bakçası kızıksız.
Anda keçkenä balalar gına yöri.
Min akvariumga barır idem.
Skatnı yañadan räsemgä
töşerer idem.
Ütkän märtäbä töşergän
räsemnärem bik uñmadı.

Skatnıñ närsä ikänen beläseñme?
Ul zur häm cäypäk balık.
Anıñ tänendä enälär bar.
Koyrıgı ozın häm ütken.
Ul suda äkren genä şuıp yözä.
Bik kurkınıç häm iskitkeç matur da.
Anıñ kebek kurkınıç zatlar
hayvan bakçasında yuk.



# Bülem 3

Bibinur apa pudelen
zooparkka alıp barırga teli.
‒ Yuk. Bili öydä kala.
Hayvan bakçasına etlär kertergä yaramıy.
Rohsät itelmi, Sofia äytä.

‒ Bikbay kön buyı yalgız
tora almıy, apa karışa.
‒ Ul kurkırga mömkin.
Berkayçan da yalgız kalganı yuk.
‒ Ännä, et öydä kala,
Sofia bik kisken äytä.

Sofia änisenä ännä dip endäşä.
‒ Sofia Elenora,
Bibinur apa süzen başlıy,
läkin şunnan uk däşmi kala.
Çönki Sofia belän söyläşep bulmıy.
Tışka çıkkanda apa işek töbendä tuktıy.
Cilineñ borının übä.
Niçä tapkır übä.

‒ Sin äle akıllı tor.
Bez tiz kire kaytırbız
dip añlata.

Cili örä.
Näni koyrıgın selketä.
Apadan kotıldım dip şatlana, uylıym.

– Oy, koyaş eşläpämne onıttım,
apa baskıçta sizä.
Ul bik yış onıta.
Yäşel tösle salam eşläpäsen barıp ala.
Eşläpä şämäha bau häm
sarı rozalar belän bizälgän.

– Äle min äzer, şatlanıp äytä dä,
eşläpäsen kiyä.

Hayvan bakçasına bez
autubus belän barabız.
Tuktalışta küp keşe basıp tora.
Bezgä karıylar.

Apanıñ östendä kızıl şakmaklı,
bigräk yämsez külmäk.
Apa bik kıçkırıp söyli.
Böten keşe söylägänen işetä.
Min anıñ söylägänen
hiç tä añlamıym,
tıñlamıy gına toram.

Küzem apanıñ zur çantasına töşä.

Çanta kömeş tösle, koyaşta yaltırap tora.
Kızık.
Kıymıldandımı?

Nihayät autubus kilä.
İñ berençe bulıp Bibinur apa kerä.
Çantasın idängä kuya da,
yänçegennän akça ezli.
‒ Vak akçamnı kaya kuydım?
ise kitä.

Artıbızda ozın çirat – balalar häm olılar –
kötep tora.
Hämmäse zooparkka barırga teli.

Balalar tınıçsızlanalar,
ber-berlären törteşä başlıylar.
Aralarınnan ber malay
arkama törtep ala da,
apanıñ çantası östenä yıgılam.

Çanta kuzgala da,
çinau tavışı işetelä.
Bu närsä… dip uylarga da ölgermim,
şunda uk çantadan Cili sikerep çıga!

# Bülem 4

– Bikbay.
Tile malay!
dip Bibinur apa kıçkıra.

Pudel autubuska yögerep kerä.
Apa anıñ artınnan yögerä.
Biletlärebezne tülärgä onıta.

Läkin min apadan elegräk ölgeräm.
Ciline autubusnıñ
urtasında totam.

Ul şatlanıp örä.
– Fu siña, tukta!
Bolay kaçıp kitärgä yaramıy,
Bibinur apa orışa.

Annarı Ciline koçaklıy.
Şunda Sofianı küräm.
Ul barıbıznıñ da yulın tülägän.
Biletlärebez kulında.
Bik açulanganga ohşıy.

– Ännä, sin Bili belän
öygä kaytasıñ.

Bez anı hayvan bakçasına
alıp barmıybız, açulanıp äytä.
Apa Cilineñ borının übä.
Sofiaga ise dä kitmi.
– Altınım, äytä.
– Küz nurım!
– Ännä, Sofia kisätä.

Bibinur apa aña:
– Sofia Elenora, äle citär.
Bez etne zooparkka alıp barabız.
Häm dä anıñ turında artık
ber süz dä yuk!
açulanıp äytä.

Sofia ni bulsa äytergä dip avızın aça,
ä apa inde autubusnıñ artına bara.
Ciline koçaklap ber urındıkka utıra.

Sofia autubusta alda
utırıp kala.
Yalgız.
– Hayvan bakçasında berkem
Biligä dikkat itmäsä yarar ide,
ä itsä, problem tua,
Sofia üz-üzenä mıgırdana.

– Filip, sin kayda kaldıñ?

Bire kil, apa kıçkıra da,
miña kölep kul izi.

Bibinur apa kotoçkıç keşe.
Ämma miña anıñ
yanına barırga kiräk.
Autubustan töşep kalır idem.
Berkayçan da bolay
oyalganım yuk ide.
Bitlärem peşä dä kızara.
Apa berni sizmi.
Lıgırdap kına tora.

Miña häm Ciligä söyli
häm dä böten autubus aşa
Sofiaga da kıçkıra.
Cilidän başka berkem
anı tiñlamıy.

Et çanta eçendä utırgan da,
keçkenä kara küzlären
apaga töbägän.

Min ni eşli alam soñ?

# Bülem 5

Nihayät autubustan töşäbez.
Sofia zooparkka kerer öçen biletlär ala.
Açulı ikänen sizäm.
Miña kalsa, Bibinur apa monı sizmi.
Berni bulmaganday Sofiaga söyli.

Sofia kergändä apanıñ çantasın yaba da,
kırt kisep äytä:
‒ Bili, äle siña äkren torırga kiräk,
tınıñ da çıkmasın.
Bolay sine tup-turı öygä ozatam.

Äle hayvan bakçasınıñ kereşendä
harita karıybız.
‒ Min iñ başta koşlar
kararga telim, Sofia äytä.
Barmagı belän koş räsemen kürsätä.
‒ Sin niçek teliseñ,
apa cavap birä.
‒ Sofia karar kılsın.
Annarı yäşel salam
eşläpäsen turayta.

Çantada Cili kıymıldana.
Apa çantasın aça.

Cili çinap cibärä.
Anıñ başı gına kürenä.
Ul çanta eçendä yabılıp
torırga yaratmıy.
Ber bik zur çitlek yanında tuktıybız.
Anda ber agaçka çuar koş kungan.
Et örä başlıy.
Koş kuzgalmıy da.

‒ Bu nindi koş?
Börket mikän? apa sorıy.
‒ Mäçe başlı yabalak,
Sofia cavap birä.
‒ Anıñ başında mögez
kebek ike çugı bar.

‒ Bik kızıklıga ohşıy,
Bibinur apa äytä.
‒ Yabalaklar artka kürer öçen
başların äyländerä alalar,
Sofia añlata.
‒ Bik küp beläseñ,
apa avır sulap ala da,
eşläpäsen turaytıp kuya.

Cilkämne sikertep alam.
Yabalaklar kurkınıç tügel.
Alar utırıp küzätep kenä toralar.

Äkren utırıp tora torgan
hayvannarnı min yaratmıym.
Haräkätle hayvannarnı yaratam.
Bigräk tä yözä torgannarnı.

İkençe, tagın da zurrak,
çitlek yanında tuktıybız.
‒ Bolar diñgez börketläre, Sofia äytä.
‒ Ber börketneñ avırlıgı cide kilo tarta.
Kanatara iñlege yakınça ike metr.
Alar kübesençä balık aşıylar.
Oyalarınıñ avırlıgı 500 kilodan artık.

Bibinur apa çitlek yanına bara.
‒ Börketlär kayda? kızıksınıp sorıy.
Nak şul vakıtta ber zur diñgez börkete
oçıp yakınnan uzıp kitä.
Kotoçkıç häm matur börket!
Tın da almıym.
Börketneñ tomşıgı ütken,
tırnakları ozın, körän tösle.

Kameramnı çıgaram.
Fotoga töşerergä telim,
läkin ul bik tiz
oçıp kitä.
İke tonık räsem genä töşerep ölgeräm.
Änä, tagın kilä!

# Bülem 6

Oy! Börketneñ ikençe kanatı
çak kına apaga timi.
– Yärdäm, Bibinur apa kıçkıra.
Apanıñ salam eşläpäsen
cil alıp kitä dä, çantası cirgä töşä.

Cili katı örä.
Çantadan çıgarga tırışa,
läkin kaça almıy.
Çantanıñ zippere kısılıp kalgan.

Apa ber-ike adım artka atlıy.
Arkası artında belderü taktası tora.
Anı sizmi dä,
tup-turı şunda bärelä.
Başın taktaga suga da:
– Ay, dip kıçkırıp cibärä.

Bik kölke küreneş. Min kölä başlıym.
Apanı tiz-tiz fotoga töşeräm.
Taktada: Çitlek yanına barırga yaramıy.
Börketlär kurkınıç dip yazılgan.

Sofia bik açulangan:
– Irjayma miña! pışkıra.

– Kamerañnı monda bir!
Min şunnan uk kölüemnän tuktıym.
Sofia kameramnı kulımnan
tartıp alırga tırışa,
ämma min tizräk kaçarga ölgeräm.
Miña yämsez karıy.
Annarı äylänä dä,
apanıñ eşläpäsen alırga yögerä.

Apa çantasın cirdän kütärä,
Cili çanta eçendä.
Eşläpäsen kiyä dä,
katı kölep cibärä.
– Bak, niçek kızık hal buldı, äytä.

Bibinur apa berni bulmaganga salışa.
Ämma Sofia kölmi.
Anıñ ike bite ap-ak.
Sofia minem kölgänem häm räsem
töşergänem öçen bik açulı.
Beraz kurkınam.
Anı min berkayçan da mondıy açulı
kürgänem yuk ide.

– Räsemne kameradan
çıgara alam, äytäm.
Sofia cavap birmi.
Miña taba karamıy da.

İrenen teşläp,
ayaklarına karap katkan.

– Filip, äle sineñ räteñ,
apa yomşak kına äytä.
– Kaya barabız?
Sin sayla.

– Min kurkınıç hayvannar
kararga telim.
Yabalaklar da börketlär
kızıksız, cavap biräm.

– Yılannar, apa täklif itä.
– Sin pitonnar
kürergä teliseñ, älbättä.

– Çınnan da kurkınıçlar
häm dä zähärlelär
bulsın, cavap biräm.
– Başkası kızıksız.



# Bülem 7

Äle bez ber zur pıyala täräzäle
bina aldında tuktalabız.
Täräzä artında koşlar häm
säyer yafraklı üsemleklär küräbez.

– Bez keçkenä altın töymäm belän
tışta kalabız, apa äytä.
– Koyaş bik matur balkıy, dip
yalgıy da eten kısıp koçaklıy.
– Eskämiyädä utırıp beraz vakıt
rähatlänäbez.

Binaga kergändä Sofia äle dä
açulıga ohşıy.
Min yomşak kına sorarga tırışam:
– Nik äniyeñ bezneñ belän
yılannar häm ürmäküçlär
kararga kermi?

Sofia ozak cavap birmi tora.
Annarı äytä:
– Ännä yılannardan kurka.
Ürmäküçlärne dä kürä almıy.
– Ahmaklık, äytäm.
– Sin ahmak, Sofia pışkırıp kuya.

Sin yaratasıñ dip başkalarga barlık
hayvannarnı yaratırga kiräkmi bit.
Üzeñ ahmak,
yalgız uylanam.
Min barlık hayvannarnı yaratam bit.
Yılannar, akulalar kebek ük şäp
bulmasalar da, alar da iskitkeç kızık.
Ämma min berni äytmim.

Min Sofiaga uylarımnı añlatsam,
ul tagın da açulırak bula.

Çayan yanında tuktıybız.
Ul baytak keçkenä.
Koyrıgı kalkıp tora da,
başı östenä beraz bögelä.
Kameramnı çıgaram.
Räsem şäp uña.
‒ Çayannar alga, artka häm
yan yakka yögerälä, beldeñme?
Sofia erelänep sorıy.

‒ Älbättä beläm, cavap biräm.
‒ Anıñ koyrıgındagı enäse genä
zähärle, beldeñme?
Sofia dävam itä.

‒ Beläm, cavap kaytaram.

– Alarnıñ ike kayçı sıman kıskıçı
häm dürt par sıyrakları bar,
anısın beldeñme, Sofia sorıy.
Anısın min belmim,
läkin belgän kebek kılanam.
Sofia tagın da täkäbberräk bulsın dip,
telämim.

– Alar cılını yaratalar, Sofia añlata.
– Çayannarga iñ azınnan
20 däräcä cılılık kiräk.
Alar köndez yoklıylar, beldeñme?
Kübesençä tönen aulıylar.
Üzemne ahmak toyam.
Bolarnı barısın da miña
belergä tiyeş ide bit.
Çayannar kurkınıç – min bit
kurkınıç hayvannar turında
barısın da beläm.
Härhaldä belgängä salışam.

– Çayannı akvariumda totıp
bulır ide, äytäm.
– Üz çayanıñ bulsa ide,
niçek küñelle bulır ide.
Şunda arkabız
artında ayak tavışları işetelä.

# Bülem 8

Bibinur apa kilä ikän.
Ul Ciline koçagına algan.
Tirä-yagın kürmi dä.
– Anda ikän sez, pufıldıy.
– İskärmästän yañgır yava başladı.
Işık urın tabarga kiräk buldı.

Apa yüeşlängän.
Cili tunın kagına.
Östebezgä su tamçıları çäçri.
– Filip çayan teli, Sofia citkerä.
– Cirängeç!
apa katı kıçkırıp cibärä.
– Äniyeñ ni äyter?

Min Sofiaga kırın gına karap alam.
Ul äle minnän üç ala.
Bibinur apa miña kanıga inde,
ä kiç belän äni mine ärlär.
Apa barısın da änigä söyli.

Sofia kölep änisenä äytä:
– Ännä, siña çäçeñne kipterergä kiräk.
Bädräf änä aldarak uñ yakta, kürsätä.
– Sez dä kiläsez.

Monda, kurkınıç hayvannar
arasında sezne yalgız kaldıra almıym,
dip nık kına äytä.
‒ Min yılannar bagarga telim.
Härhaldä miña alarnı
fotoga töşeregä kiräk, äytäm.
Sofia änisenä:
‒ Bezne maymıllar
yanında köt, dip äytä.

Min Sofianı añlamıym.
Başta miña açulı da,
annarı bulışa.
Närsä uylıy ikän?
Sorarga telim, ämma kurkam.
Sofia pıyalaga borının törtep,
keçkenä kältägä karap tora.

‒ Gekko. Bu kältä gekko,
Sofia añlata.
‒ Anıñ ayaklarında vak yonnar bar.
Alar yärdämendä ul divarlarga da
tüşämnärgä menälä.
Ul böcäklär belän tuklana.
Faydalı hayvan.
Äydä!
Äle yılannar yanına barabız,
dip Sofia çakıra.

# Bülem 9

Anakonda yatkan, yartı gäüdäse suda,
ikençe yartısı komda.
Arabızda pıyala divar gına.
Yılannıñ başın da koyrıgın da
kürä almıym, urtasın gına.

– Bu yäşel anakonda.
Sofia añlata başlıy.
– Ul un metr ozın häm
200 kilodan kübräk tarta.
Anakonda dönyanıñ iñ zur häm
iñ avır yılanı dip sanala.

– Dönya kadär zähärleder dä, äytäm.
– Hiç tä tügel. Sofia karşı kilä.
– Ul teşli, läkin zähärle tügel.
Eläktergän tabışın anakonda bua.
Krokodilnı da bua ala.

– Kızık. Anı ul niçek eşli? sorıym.
– Totkan tabışın gäüdäse belän
urap ala da, katı gına bua. Ämma,
Filip, siña kurkırga kiräkmi.
Sin tämle tügel. Ketchup belän dä.
– Ha-ha, bik kızık, açulanıp cavap biräm.

# Bülem 10

Bibinur apa maymıllar binası yanında,
ber çitlek aldında Cili belän bezne kötä.
Ciline bauga bäylägän.
Çitlektä ber maymıl yäşi.

Çitlekneñ räşätkäläre arasınnan
kulnı kertep bula.
Annan maymıl da kulın suza ala,
läkin üze tışka çıga almıy.

Maymıl keçkenä küzläre
belän bezne küzätä.
Ul ber agaç botagına utırgan da,
arkasın kaşıp tora.
Zararsızga ohşıy.

– Kızıksız, mıgırdanam.
Çitlek räşätkäse yanına baram da,
kameramnı çıgaram.
– Filip, bik yakınga barma.
Maymıl eşläpämne alırga
tırıştı inde, apa kisätä.

Belderü taktasındagı yazunı ukıym:
Vakıtlıça çitlek. Saklan!

Maymıl urlarga yarata.
Dulkınlandıra torgan hal!

Maymılnı räsemgä töşerergä äzerlänäm.
Kameranı çitlekneñ eçke
yagına kertäm dä,
ber räsem töşeräm.
Tagın ber kat çirtäm.
Öçençe räsemne töşergändä
maymıl sikerep töşä dä,
kameramnı kulımnan tartıp ala.

Apa ilerä, Cili örä.
Et çitlekkä kerergä tırışa,
läkin apa anı bavınnan tartıp kıçkıra:
– Ul pıçrak maymıl.
Betläre dä bardır.
Bili! Yakınına barma.
Tiz genä pudelne çantasına tıga.
Et örüennän tuktıy.

Min maymılga bik katı kızam.
Çitlek räşätkäsen ike kulım
belän totıp dañgırdatıp selketäm.
Maymılga yämsez süzlär kıçkıram.
Bähetemä, apa miña dikkat itmi.
Yämsez süzlär söylärgä äni miña
rohsät birmi bit.

Sofia gına tınıç.
Miña äytä:
– Tukta. Sügenep torma.
Faydası yuk.
Maymıl barıber söyläveñne añlamıy.

Läkin min Sofianı tıñlamıym.
Maymıl kameramnı vata
inde dip kurkam.
Kameramda bik küp
matur räsemnär bar.

Maymıl botakka utırıp,
kameram belän uynıy.
Kameramnı teşli.

Min kıçkıram:
– Tukta, idiot.
– Sin üzeñ idiot,
Sofia mıgırdıy.
– Maymıl döresen äytkändä marakatt.
Kameranı aşap bula dip uylıy.

Maymıl kameranı idängä bärä.
Böten gäüdäm suınıp kitkänne sizäm.

# Bülem 11

Maymıl sikerep töşä dä,
kameranı kütärep ala.
Anı tırnıy, agaçka suga.
Töymäsenä kat-kat basa.

Kameram vatıldı inde,
şik tä yuk.
– Kameranı kokos çiklävege dip
uylıy yäki başka ber katı
çiklävek, Sofia hıhıldıy.
– Barıber, Sofianıñ süzen büläm.
– Kameramnı gına telim, äytäm.

– Sofia Elenora,
karauçı tabarga kiräk,
Bibinur apa berni eşlärgä dä belmiçä kıçkıra.
– Sin genä bar, Sofia cavap birä.
Apa çantasın cirgä kuya, eçendä Cili.
Annarı maymıllar yortınnan
yögerep çıgıp kitä.

– Filip, hayvan bakçasınıñ haritası sindä bit?
Sofia sorıy. – Anı miña bir.
– Harita belän maymıl arasında nindi
bäyläneş bar ikän, dip acäplänäm.

– Bir anı monda,
Sofia pışkırıp äytä.
Nigä anarga harita kiräk,
min añlamıym,
alay bulsa da biräm.
Sofia kulın räşätkä arasınnan kertä dä,
haritanı selki başlıy.

Maymıl kamera çäynävennän tuktıy.
Yakınrak kilä.
Harita anı kızıksındıra kebek.

– Kameranı monda bir, maymılga kıçkıram.
– Äkren tor, Sofia kisätä.
Maymıl şunda kurkınıp ölgerä dä,
agaçka sikerep kaça.

Sofia haritanı tagın selki:
– Monda kil, yomşak kına endäşä.
Maymıl saklanıp kına kulın
haritaga taba suza.
– Kameranı miña bir, Sofia tübän
tavış belän äytä.

Maymıl başın kırın sala.
Uylap utıra da, kolak artın kaşıp ala.
Yuk, ul telämi.
Ul agaç botagında utırıp kına tora.

Bezgä şiklänep karap tora.
Kameramnı berkayçan da ala almıym inde.
Yünsez maymıl minem şäp kameramnı
üzendä totarga teli.
Min maymıllarnı yaratmıym.

– Ännäneñ çantasında ber
kapçıp çiklävek bar, Sofia pışıldıy.
Apanıñ çantasın ala dä kazına.
Çiklävek yuk.
Cili maymılnı tagın kürä dä örä.

– Tukta! Sofia äytä.
– Bolay tavışlarga yaramıy.
Kem bulsa sine kürer dä,
bezne öygä ozatır.

Cili maymılnı kürmäsen dip
Sofia çanta zipperen yaba.
– Kesämdä lakritsa bar,
läkin ul maymıllarga yahşı tügel.
Yäşelçä, çiklävek yäki cimeş kiräk,
Sofia üzaldına söylänä.

– Hayvannarnı aşatırga yaramıy.
Belderü taktasında şulay yazılgan, äytäm.
– Dimäk, kamerañnı berkayçan da
alalmıysıñ, Sofia äytä.

# Bülem 12

Cimeş?

Kapılt itep isemä töşte.
Mindä ber cimeş bar bit.
İrtä belän, öydän kitkändä,
äni biştäremä ber banan salgan ide.
Banannı çıgaram da,
Sofiaga biräm.
Ul anı beraz arçıy da çitlek eçenä suza.

– Menä, banannı tämläp kara,
teleñne yotarsıñ, maymılga äytä.

Maymıl agaçtan sikerep töşä dä,
banannı alırga tırışa.
Sofia kulın tiz genä kire tarta.

– Yuk, yılmayıp äytä.
– Başta kameranı miña bir.
Annarı siña banannı birermen.

Maymıl arkasın kaşıy da uylana.
Ber kulı belän çitlek räşätkäsennän
totıp tora, ikençe kulında kamera.
Banan anı kübräk kızıksındıra.

Kameranı kulınnan ıçkındıra da,
ul idängä çitlek räşätkäse yanına töşä.
– Al anı, Sofia miña pışıldıy.
Tiz ük kenä kütärep alam.
Tagın kamera belän
uynıy başlamasın gına.

Maymıl banannı ala da,
sikerep agaçına kayta.
Anda banannı arçıy da,
aşap kuya.



# Bülem 13

Sofia kameranı kulımnan ala.
Töymäsenä basa.
Kamera vıjıldıy.
Maymıl utırgan, aşıy.
Anı räsemgä töşerä.
– Kamerada teş ezläre bar,
läkin eşli, Sofia belgertä.

Apa hayvan karauçısı belän eçkä atıla da:
– Maymıl tegendä.
Ul Filipneñ kamerasın aldı dip kıçkırıp äytä.
– Kamera mindä, kütärep kürsätäm.
Kameramnı kire alaldım dip
rähatlänep kittem häm şatlandım.
– Vatılmagan. Östendä teş ezläre
genä bar, yalgap cibäräm.

Kemneñ kamerasında teş
ezläre bar ikän!
Şatlıgımnan köläsem kilä.
Berkemneñ dä kamerasında
maymılnıñ teş ezläre yuk!

– Böten zooparknı yögerep äyländem,
apa pufıldıy.

– Tınıçlanıgız, karauçı äytä.
– Mäsäläne niçek hal ittegez,
anı añlatıgız.
Sofia banan turında añlata.
Anıñ banan aşatkanı öçen abıy
açulanır dip uylıym.
Yuk, ul kölä genä.

– Osta, tapkır ikänseñ, abıy äytä.
– Sin hayvannar turında küp beläseñ, küräm?
– Min hayvannar yaratam.
Hayvannardan kızıgrak närsä yuk.
Min hayvannar tabibı bulırga telim,
veterinar, Sofia därtlänep añlata.
– Monda eşkä rahim it.
Bezgä yahşı veterinarlar kiräk, karauçı äytä.

Bibinur apa süzne bülä:
– Sofia Elenora äle keçkenä.
Aña äüväl mäktäben tämamlarga,
annarı universitetta ukuın
dävam itärgä kiräk.
– Min beläm, Sofia üzsüzlänä.
– Veterinar bulırga uylıym.

– Äybät. Añlaşıldı, karauçı äytä.
Sofiaga kul birä dä, yulın dävam itä.
Sofia bik gorur kürenä.

Min dä täesirlänäm,
ämma läkin hisläremne kürsätmim.
Sofia hayvannar turında
minnän şaktıy kübräk belä.

Kuzinım bik belemle
Min aña gorurlanam.
– Rahmät. Kameramnı
kotkarganıñ öçen, rahmät,
mıgırdanıp Sofiaga äytäm.
– Berni tügel, Sofia cavap birä.

Äle inde Sofianıñ çınnan da
küp belgänen añlıym.
Miña äldä küp öyränergä kiräk.
Anı da añlıym.

Kameramnı yahşırak
saklarga kiräk.
Maymıl anı eläkterde,
ul minem üz hatam ide.

Apa Ciline çantadan
alıp çıgarıp cibärä.
Ul maymılga örä başlıy.

Maymıl banan kabıgın
tota da Cilineñ östenä bärä.

# Bülem 14

– Äle min ber çaşka kahvä
eçär idem, Bibinur apa äytä.
– Anıñ belän genä nervalarım tınıçlana.
Bötenläy bettem.

– Kurkıngaç, haman da ännämneñ
aşıysı kilä, Sofia añlata.
– Minem dä äniyemneñ açuı kilgändä yäki
kurkınsa aşıysı kilä, äytäm.

İskärmästän Sofia yılmaya.
Berençe tapkır anıñ yılmayganın küräm.
Yılmayganda ul çınnan da söykemle.

– Min waffle telim.
Häm dä tuñdırma belän,
Sofia kıçkırıp cibärä.
– Min dä telim.
Min şokolad belän, şatlanıp äytäm.

Hayvan bakçasınıñ kafesına barabız.
Apa zur çaşka kahvä belän
kaynatmalı kümäç ala da:
– Miña äzdän ber litr kahvä kiräk.
Bolay huştan kitäm, dip añlata.

– Yuknı söylämä! Sofia mıgırdıy.
– Sin bik ciñel huştan kitmiseñ.

Kafenıñ işek aldındagı
ber östäl artına barıp utırışabız.
Anda berkem dä yuk dip äytep bula.

Sofia belän wafflelarıbıznı aşap kuyabız,
läkin apa aşıkmıyça gına kahväsen eçä.

Cili apanıñ ayak töbendä yatkan,
borının täpiläre östenä kuygan.
Arıganga ohşıy.
Bibinur apa muyınçagın alıp kuya da:
– Äle yal itä alasıñ, äytä.
– Kara nindi matur koşlar,
barmagı belän kürsätä.
– Koyrıgında ozın kaurıylar
bulganı iñ maturı.
Ul fazandır?

– Ännä, ul koş tävis, Sofia äytä.
Tävis tomşıgın aça da,
yämsez tavış belän kıçkırıp cibärä.
Apa siskänep kitä dä:
– Oy, niçek yämsez kıçkıra.
Öräk tavışı kebek.
Koş niçek bolay şomlı kıçkıra ala?

Ber akçarlak havadan atılıp töşä.
Ul apanıñ kümäçen urlarga tırışa.
‒ Kül akçarlagı, Sofia äytä.
‒ Anıñ başı kara.
Bak! Änä, tagın kilä, kürsätä.
‒ Yaman koşlar, apa kıçkıra da,
kulları belän koşnı kua.
Akçarlak oçıp kitä.

Yanıbızdagı östäldä kargalar häm
çıpçıklar sikerenep tora.
Anda kemder aşagan da,
ikmäk valçıkları östäldä kalgan.

‒ Karagız, kargalar nindi matur koşlar,
Sofia äytä. Kameramnı ala da,
äkren genä koşlar yanına bara.
Cili aña iyärä.
Ul eskämiyä östenä sikerä dä, örä.
Koşlar oçıp üz yullarına kitälär.
‒ Kurkıtırga kiräkme ide? Sofia sorıy.

Cili koyrıgın cilferdätä.
Bibinur apa äytä:
‒ Zihenle et.
Koşlar häryaknı pıçıratalar gına.
Tuydırgançı kıçkıralar da.
İskärmästän kafedan eçtän tavış işetelä.

# Bülem 15

Kafedan halık yögerep çıga.
İñ berençe bulıp ozın
çäçle kız çıga.
Ällä nindi keçkenä hayvan bezne
sikerep uzıp kitä.

Närsä ikänen kürergä
ölgermim, läkin Sofia belä:

‒ Mangust,
dip därtlänep añlata.
Äle min dä anı küräm.
Ul körän tösle, zur as sıman.
Koyrıgı kalın häm ozın.

Cili anıñ artınnan atılıp kitä.
Anıñ kıska ayakları cirdä döberdi.

‒ Tukta, apa kıçkıra.

Ozın çäçle kız häm ber-ike
karauçı taudan aska taba yögerälär.
Alar mangustnıñ bezne uzgıp
kitkänen sizep ölgermilär.
Başka yakka baralar inde.

– Tiz genä,
Sofia kıçkıra.
– Ciline totıp bäylärgä kiräk.
Ul mangustnı teşläp
üterergä mömkin.
Filip sin uñga kit,
min sulga kitäm.

– Sofia Elenora, yuk,
apa kisätä başlıy.
Bez anı işetmibez.
Änä, Cili belän mangust.
Yuk, tagın yugaldılar.

– Tukta, Cili, kıçkıram.
– Monda kil!

İkese dä yugaldılar.
Tın alırga tuktıym.
Min kaya kildem ikän?

# Bülem 16

Biredä zur, biyek,
pıyala divarlı çitleklär.
Össläre açık.
Dimäk, koşlar öçen tügel.
Koşlarnıkı tübäle bula.
Kaya taba barırga ikän dip
uylanıp toram.
İke yul bar.
Kaysın saylarga?

Cilineñ örgänen işetmim inde.
Ul bik yırakta.
Uñga kitimme, sulgamı?

Şunda uylanıp torganda küzem
bik kızık närsägä töşä.
Ber çitlektä, cirdä,
nidider ak närsä yata.
Zur tiregä ohşıy.
Tire kıymıldana.
Avızı açıla.
Zur, açık, kızıl tamagın häm
ike ütken algı teşen kürep alam.

Oy!

Tire dönya kadärle zur mäçe ikän.
Äkren genä yatkan urınınnan tora.
Täpiläre zur.
Koyrıgı bik ozın.
Koyrık oçında kara çuk.
Mäçe avızın tagın da aça.
Min dä isnämiçä tora almıym.

Üz-üzemä äytäm:
– Filip, siña äle yoklarga yaramıy.
Ciline tabarga kiräk.
Ul mangustnı teşläp üterergä
ölgermäsen genä.
Çitlek yanında belderü.
Kızıksınıp karıym. Elegräk
mondıy mäçe kürgänem yuk ide.

Belderü taktasında yazılgan:
Ak bars.
Mäçe bötenläy ak tügel ikän.
Tunında kara taplar bar.
Äle kiyerelä dä, çitlektä äylänep yöri başlıy.
Äkren häm yomşak täpili.
İnde yämle häm zifa buylı!
Minem mondıy näfislekne berkayçan da
kürgänem yuk ide.

– Sin iskitkeç matur, ak barska äytäm.

Kameranı çıgaram.
Äle!

Ak bars näk aldıma baskan.
Räsemgä töşergändä, kamera utı örelep ala.
Flashne sündererergä onıtkanmın.
Ak bars tuktıy.
Yäşkelt küzläre belän mine küzätä.
Kuzgalmıy, läkin mırıldıy.
Kurkıtır öçen koyrıgın selketä.

Ak bars kurkınıç.
Min anı yaratam da,
beraz añardan kurkam da.
Uylap karaçı, ul keşe aşasa!
Şöker, çitlekneñ divarları pıyaladan.

– Akıllı mäçe. Açulanma.
Flash kenä ide bit, äytäm.

Ak bars tagın mırıldıy da,
miña arkası belän borıla.
Kullarım kaltırıy.

Kinät Cilineñ örgänen işetäm.

# Bülem 17

Kameramnı kesämä salam da,
örgän tavışka taba yögeräm.
Tavış kayan kilä ikän soñ?

Äle Ciline küräm.
Ul ber çitlek aldında kotırınıp örä.
Çitlek yanına baram da,
seläüsengä örä ikän dip küräm.

Seläüsen ak barska
karaganda keçkenäräk.
Koyrıgı da bik kıska, özek kenä.
Saklanıp Cili yanına baram.
Miña bit anı totarga kiräk.

Äle tota almasam,
berkayçan da tota almıym!
Eşem uñmıy.
Ul bik osta kaça.

‒ Bire kil, Ciligä kıçkıram.
Mine tıñlamıy.
Min yakında bulgannı kürmägängä salışa.

Seläüsen çi it aşıy.

Cili çi it isen sizä torgandır.
Şunıñ öçen kotırıngan.
Açıkkandır da inde.
Berniçä tiz adım atlıym da,

Cili östenä taşlanam.
Ul sikerep kitä dä,
min lap itep eçem östenä yıgılıp töşäm.

Cili mıskıllap kölgän kebek örä.
Ayagürä toram.
Sul tezem avırta.
Anı baya taşka bärdem bit.
Yögergändä aksıym.

Cili mine nık kına açulattı.
Tagın tegendä!
Arıslannar çitlege aldında
mangustnı kua.
Min alar turısına citkäç ük,
ikese dä yugala.

Min arıslannarnı yaratam.
Alar kurkınıç.
Alarnı räsemgä töşerergä telim dä,
vakıt yuk.

Cili kaydadır yırakta kotırınıp örä.

Sofia andadır.
Cilineñ bavı da añarda,
ul etne totsın.
– Sofia, kıçkıram.

Cavap yuk.
Min yapa-yalgız.
Yuk, min yalgız tügel ikän.

Mangust kinät karşıma yögerep çıga.
Ul ällä närsäne kua.

Ciline tügel.
Pudel kayda soñ?
Berkayda da kürenmi.

Mangnust närsäne kua?

# Bülem 18

Ällä nindi ozın kolaklı,
körän tösle,
sikerä torgan zat.
Yort kuyanı, kanin ikän!
Ul tup-turı miña taba kilä.
Bik katı kurkıngan.

Min nişlim?
Tiz genä uylap karıym.
Kuyannı mangusttan kotkarırga kiräk.
Ber kulım belän kuyannı totsam,
ikençese belän mangustnı totarmın.

Kullarımnı açıp,
kuyanga karşı yögeräm.
Ul kaçarga tırışa.
Bähetemä, anı tota alam.
Tiz genä kuyannı koçaklap kütäräm.
Ul totkannı yaratmıy.

Artkı täpiläre belän tibenä.
Keçkenä bulsa da, köçle ikän.
Algı täpiläre belän kükrägemä kaga.
Kulımnan kotılırga tırışa.
Kolakları yassılanıp, arkasına sılangan.

Mangust minem tirämdä biyep tora.
Pışıldıy da, sikerenä.
Äle küräm, ul körän belän ak tösle.
Mangust ta, döresen äytkändä,
baytak söykemle.
Borını oçlı.

Äle mangust kuyannı teşlärgä tırışa,
ämma kuyan urınına mine teşli.
Ütken teşlärennän belägemä
yara kala.
Ul avırta, kanıy başlıy.
‒ Ay, kıçkıram.
Kuyan kulımnan ıçkına.

Cirgä sikerep töşä dä,
mangust artınnan çaba.
Kuyannı tagın totarga kiräk.
Bolay anıñ canı kurkınıç astında.
Mangust belän kuyan öçen yarışabız.
Mangust kuyannı totam digändä,
min eläkterep alam.

‒ Tukta, şaulama,
mangustka kıçkıram.
Mangust baltırımnı teşli.
Miña Sofianı yäki başka
beräüne tabarga kiräk.

Kem mangustnı tota ala?
Ber ük vakıtta kuyannı kotkara häm
dä mangustnı tota almıym min.
Miña yärdäm kiräk.

Yögerä başlıym.
Kaysı yakka yögergä, belmim.
Yırakta aldarak tavışlar işetäm.
Kemder kıçkıra.
Anda taba köçemnän kilgän
kadär tiz yögeräm.

Mangust artımnan kilä dä,
çälteremne çemetep ala.
Min abınıp kitäm.

Niçek tä añardan kotılalmıym.
Äle inde tubıgımnı dä teşli.

Kayda böten keşelär?
Nigä häryak tındı?

Kuyan koçagımda tavışsız tora.
Min aptırap kalam.

Üldeme?
Kısıp üterdemme?

# Bülem 19

Kuyannı arkasınnan sıypıym.
Köçkä ayagürä tora alam.
Kinät yılıysım kilä.
– Akıllım, ülmä, mıgırdanam.

Annarı kuyannıñ yöräk kagışın toyam.
Ülmägän.
Yäşi, läkin bik katı kurkıngan.
Şunıñ öçen tıp-tın tora.
Kara küzlären yomgalap tora.
Söykemle.
Mañgay çäçe bar.
Ber kolagı beraz yırtılgan.
Äle yöräge äkrenräk suga.
Artık kurıkmıy.
Yäki bik kurka.

Yöräge tuktarga tora?

Mangust tagın kuyannı teşlärgä tırışa.
Ul yırakka sikerep kitä.
Kuyannı kotkarırga kiräk.

Niçek buldıra alam ikän?
Beraz gına açık kalgan işek küräm.

Şunnan yögerep kerep,
işekne yabıp kuysam.
Läkin ber mäsälä bar.

Niçek kerergä?
Mangust artımnan kerälä.
Belmim, ämma tırışırga kiräk.
Häm dä tiz buldırırga kiräk.
İşek yanına citkäç,
kuyan eçemä tibenä dä,
kulımnan kotılıp kitä.
İşektän atılıp eçkä kerä.

Osta kuyan!
Eçtä kurkırga kiräkmi.
Mangust tabanımnı teşläp tora.
Ul kuyan artınnan citärgä tırışa.
İşekne kalgan köçem belän
mangustnıñ borını aldında
şap itep katı yabam.

Mangust tışkı yakta kala.
İşek räşätkäse arkılı kerergä tırışa,
läkin sıymıy.
Yämsez tavışlar çıgara.
Buldırdım.

Kuyannı kotkardım!

Tirän genä sulap alam.
Böten gäüdäm kaltırana.
Belägem kanıy.
Kannı tuktatır öçen
kulyaulık kiräk.
Kesämdä kazınam.
Külmägem kan belän buyala.
Kesämdä kulyaulık yuk.

Haman şulay!

Biştärem kayda?

Äle miña biştärem kiräk,
läkin ul apam yanında kafeda kaldı.

Äni biştäremä haman ber paket
kägaz kulyaulıklar kuya.

Häm dä bez äle kayda?

# Bülem 20

Külmägemdäge kannı sörtep alam.
Äni açulana inde,
läkin äle başka berni dä
eşli almıym.
Kannı tuktatırga kiräk.
Belägemne gäüdämä karşı kısam.
Külmägemneñ ciñe
cılına da dımlana.

Nigä borınıma bik
sası is bärelä?

Äle genä sizäm,
min çitlek eçendä ikän.
Bu çitlek artında tagın
ber zurrak çitlek bar.

– Filip, äle siña uylarga yaramıy.
Uylasañ, kurkasıñ gına,
katı tavışka üzaldıma söylänäm.

Läkin miña uylarga kiräk.
İşek açık ide.
Dimäk, bu keçkenä çitlek
buş bulırga tiyeş.

Bälki dä monda toruçı hayvan
kaçıp kitkänder.

Bu mangustnıñ çitlegeme ikän?
Yuk, ise başka.
Mangusttan mondıy is kilmi.
Cirdä zurrak hayvannıñ ezläre bar.

Kaysı hayvannıñ ezläre ikän?

Kurka başlıym.
Tirä-yagıma da
kararga kurkam.
Nindi genä hayvan bula ala.
Ezlär zur mäçe
hayvannıkına ohşıy.

Uylap kara,
ägär dä ak bars bulsa?

# Bülem 21

Çitlek eçendä toru yaman.
Uylap kara, berkayçan da
monnan çıga almasam?
Uylap kara, berkem dä mine tapmasa?
Hayvan mine aşap kuysa.
Panikaga bireläm,
küñelem bolgana başlıy.
‒ Yärdäm, kıçkıram. ‒ Yärdäm!
Berkem dä mine işetmi.
Mangust ta kürenmi.

Saklanıp kına işekne açarga tırışam.
İşek biklängän.
Biredä hayvannar böten omerlären
räşätkä artında yäşilär.
Härkön halık kübäüläp kilep
alarnı küzätep yöri.

Hämmäse räsemgä töşerälär,
barmakları belän kürsätep toralar.
Äle mine kem dä karap tormıy.
Barısı da karap torganda
niçek toyıla ikän,
küz aldıma kiteräm dä uylanam.
Yamandır.

İşekne dañgırdatam.
Kuzgalmıy da.
Mangust eçkä kerälmi,
ä min tışka çıgalmıym.
Kuyan kayda?

Ul cirgä tişek kazıy başlagan.
Çitlektän çıgarga teli.
Ägär dä işek astınnan üzenä
yul kazıp çıgarsa,
mangust anı tota alır mikän?
Ul, şik tä yuk, yakındadır.
İşek yanında saklap toradır.
Kuyannıñ sikerep çıkkanın gına kötep toradır.

Min kuyannı kütärep koçagıma alırga
tırışam, ämma ul kaça.
Kolagınnan eläkteräm.
Kolakları bik näzekkä ohşıy,
ämma tirese nık, yırtılmıy.

Kuyannı koçagıma kütäräm dä,
kükrägemä kısam.
Çitlektän kaçmasın dip
anı nık totarga kiräk.
Kuyan äkren tora, tavışlarga da tırışmıy.
Başın kultıgıma kaçıra.
Min dä kaçarga telär idem.

Kuyannı totıp torganda,
üzemne rähat his itäm.
– Sin yahşı dus,
kolagına pışıldıym.
Artımdagı zur çitlektä kurkınıç hayvan.
Häryakka kurkınıç is taralgan.

Min kurkınıç
hayvannarnı yaratam.
Alar belän ber çitlektä
torırga gına telämim.
Hayvannarnıñ urını
räşätkälär yäki
pıyala divarlar artında
yäki dä akvariumda.

– Min berkayçan da akulanı
kulga iyäläşterergä telämim,
kuyanga pışıldıym.
– Kıskası, kurkam.
Döresen äytkändä,
kurkınıç hayvannardan kurkam.
Anı sin genä belep tor.
Berkemgä dä söylämä.
Bolay monnan soñ
miña berkem dä ışanmas.
Kileştekme?



# Bülem 22

Kuyan borının tagın da
tiränräkkä kultıgıma tıga.

‒ Kurkınıç tügel,
dip anı pışıldap tınıçlandıram.
Min üzem hiç tä tınıç tügelmen.
Hiç tä.

Bik kurkam,
uylarga da halem yuk.
Alay bulsa da, böten vakıt uylıym.
Telämäsäm dä, miyem eşläp tora.
Barısın onıtırga gına telim.
Bu naçar töş kebek.

Miña nişlärgä kiräk, kinättän beläm.
Çitlek eçendä, cirdä,
ber botak yata.
Anıñ belän räşätkägä kaksam,
bälki kemder işeter.

Ämma botak yanına
kurıkmıyça bara alammı?
Tege kurkınıç hayvan,
hiçşiksez, yakında.

‒ Filip, saklanıp, äkren genä yör,
üz-üzemä äytäm. Ayak oçlarına basıp,
botaknı barıp alam.
Annarı işek yanına kire yögeräm.
‒ Ahmak mangust.
Barısı da sineñ ayebeñ,
katı tavış belän äytäm.

Botak belän räşätkägä kaga başlıym.

Çañ! Çañ! Çañ!
Kuyan siskänä.
Kurkına da,
koçagımnan sikerep töşärgä tırışa.
Tagın ber tapkır räşätkägä sugam.

Faydası yuk.
Tavış citärlek köçle tügel.
Katırak tavışlarga kiräk.
Zur çitlektäge hayvannı borçısam, ni bulır?

‒ Bernindi dä hayvan yuk.
Üzeñ uylap çıgarasıñ, Filip,
üz-üzemä äytäm.

Täväkkäl bulırga kiräk.
Citärlek katı tavışlasam,
kemder mine işetep tabar ide.

Räşätkägä katırak kagam.
Sukkan sayın kuyan kaltırana.
Berkem dä kilmi.
Artık kakmıym,
çönki kulım arıdı.
Kulnı almaştıram.
Avırttırgan kulımnıñ köçe ber tapkırdan
artık sugarga citmi inde.
Utırıp yal itärgä kiräk.

Şunda ällä närsä arkam artında mırıldıy.
Tübän, kurkınıç tavış.
Şul uk sekuntta Cilineñ örüen işetäm.
Örü tavışı yıraktan kilä.
Anı kıçkırıp çakırırga kiräk.
Etlär yahşı işetä.

– Cili, bire kil, kıçkıram.
Örüen yakınraktan işetäm inde.
– Cili, monda, malay! kıçkırıp endäşäm.

Nihayät, etne küräm.
Küzemnän yäşlär aga başlıy.
Halem ciñeläyep kitkängä yılıym.
Berniçä tamçı yäş kuyannıñ
östenä dä tägäräp töşä.

# Bülem 23

Cili dönyanıñ iñ äybät ete.
Monnan soñ berkayçan da aña açulanmıym.
Sofia Ciline muyın bavınnan totıp,
artınnan yögerä.
‒ Sofia, min monda,
köçemnän kilgän kadar kıçkıram.
Cili işek yanına yögerep kilä dä, örä başlıy.
Tışkı yakta mangust kötep yata.
Cili anı kurkıta.
Mangust tagın sikerä dä bi´i başlıy.
Anısın beldem inde! Ul işek töbendä
böten vakıt kuyannı kötep yatkan.

Cili mangustnı totarga tırışa,
läkin Sofia muyın bavın katı tota, cibärmi.
Sofia äkren genä işek yanına kilä.
‒ Hey Filip. Oy sine, äytep cibärä.
Sofianıñ küzläre kurkuınnan zuraya.
Miña turı karamıy. Arkam artında nider kürä.
Böten tänem boz kebek bula.
Arkamnan suık dulkınnar ütep kitä.
‒ Oy inde, Sofia tagın äytä dä, annarı kölä.
‒ Kurıkma! Äkren genä äylän.
Kurkınıç hal tügel.
Arkañ artında yulbarıs baskan.

# Bülem 24

Ayaklarım totmıy. Yulbarıs!
Keşe aşıy torgan kurkınıç yulbarıs.
İşekkä söyäläm.
Min yulbarıs çitlege eçendä.
Yakında kurkınıç hayvan bar
dip beldem bit.
Hayvannıñ karaşın arkamda sizdem,
läkin yulbarıs bulganın belmädem.

Sofia tınıç kına añlata başlıy:
‒ Yulbarıs eçtäge çitlektä,
ä sin tıştagısında.
Anıñ buyı siña citmi.
Küräseñme, ul nindi matur? sorıy.

Äkren genä äylänäm.
Äle yulbarısnı küräm.
Räşätkä arkılı mine küzätä.
Küzläre sarı, borını kiñ.
Mırıldaganda ozın ütken teşlären kürsätä.

Yulbarıs bik yakında.
Ägär dä ike adım atlasam,
mıyıgına totına alam.
Yulbarısnıñ täpiläre kuyan kebek zur.

Yuk, yulbarısnıñ täpiläre kuyannan zurrak.
Sofia çitlekneñ tışkı yagındagı
belderü taktasın ukıy.

‒ Bu seber yulbarısı, äytä.
‒ Ul döyanıñ iñ zur mäçe
hayvannarınnan sanala.
Seber yulbarısları arıslannan zurrak,
beldeñme?
Adättä yulbarıslarnıñ buyı
ike-öç metrga hatle.
Koyrıgı belän öç metr ozınlıkta bula.

‒ Rahmät, äytäm.
‒ Citte. Añardan is çıga.
‒ Älbättä, Sofia äytä.
‒ Ul bit keçkenä çitlektä tora.
Tışta, urmanda ul azat yäşi, ise çıkmıy.

Yulbarıs kurkınıç ta,
şul uk vakıtta matur da.
Avızı kanga buyalgan.
Küzem kanga töbälä.
‒ Ul hazer gına aşagan,
Sofia barmagı belän kürsätä.

Yırakta arttarak, çitlekneñ ber çitendä
söyäklär häm ber zur kisäk it yata.

Şuña yulbarısnı elegräk sizmädem.
Ul poçmakta aşap yatkan.

– Äle sine monnan
çıgarırga kiräk,
Sofia äytä.

– Min barıp ber karauçı
çakıram.
Kurıkma.
Seber yulbarısları
ifrat kurkınıç,
ämma sin buldırasıñ.
Sineñ haman
bäheteñ bar.
Keçkenä pesikäy belän
küñelle vakıt ütkär!



# Bülem 25

Sofia Ciline räşätkägä bäyläp kuya.
Annarı üz yulı belän yögerep kitä.
Min kurıkmıym. Kurkudan korıç kebek kattım.
Cavap kaytarırga da köçem yuk.

Yulbarısnı küzätäm, ul mine küzätä.
Yulbarıs mırıldıy.
Tamagınnan katı mırıldau tavışı çıga.
Sarı küzlären yomgalamıy da.
Başımnı äyländeräm, aña karamıym.
Arkam belän işekkä sılanam.

Şunda yulbarıs avızın aça.
Zur avızı eçendä ozın rät teşlär küräm.
Zur täpiläre belän räşätkäne
niçek kenä ciñel vata alır ide.
Mine aşarga teläsä, anı da eşli ala.
Bälki ul äle dä aç.

Cili çitlekneñ tışkı yagında
mangustka çınıy da örä.
Mangust pudelneñ äylänäsendä bi´i
dä anı ürtäp tora.
Niçek ozak ber-berebezne küzätep tordık,
anısın belmim.

Ber yıl dip toyıla, yuk, yöz yıl.
Kinät tavışlar işetelä başlıy.
Sofia işek yanına yögerä.
– Filip, haleñ niçek? tını betep pufıldıy.
– Äle azat bulasıñ. Menä açkıç.

Karauçı abıy da Sofiaga iyärep yögerä.
– Oy! karauçı äytä.
– Niçek sin anda çitlek eçenä eläkteñ?
Bez bu keçkenä çitlektän yulbarısnı aşatabız.

Karauçı işekne açkıç belän aça.
Çitlektän kuyannı koçaklap,
abınıp-abınıp çıgam.
Mangust tavışlıy da, sikerä.
Kuyannı teşlärgä tırışa, ämma
adaşıp minem belägemne teşli.
– Äle citte, açulanıp kıçkıram.

Cili mangust artında örep tora.
Ul Mangustnı teşlärgä tırışa.
Karauçı çitlekne bikli.
Sofia Ciline tota. Ul örüennän tuktıy.
Karauçı mangustnı iñsäsennän totıp kütärä.
– Kara, sin nindi şuk, mangustka äytä.
– Minem belän bar.
Bu kaçkınnı kire
hucasına kaytarabız.

# Bülem 26

Mangustnıñ fikere başka.
Ul kirelänä dä, karauçınıñ kulınnan kotıla.
Ciline teşlärgä tırışa.
Karauçı anı tagın totıp ala.
‒ Tege mangust, min süzgä kereşäm.
‒ Ul mangust tügel, Sofia süzemne bülä.
‒ Yalgış karaganmın.
Ul kulga iyäläşkän közän.
‒ Ul teşli, äytäm.
‒ Uynıy gına, Sofia äytä.
‒ Uynaganda teşli dä.
Läkin sineñ koçagıñda närsä?

‒ Yort kuyanı, äytäm.
‒ Mangust ‒ yuk, közän
kuyannı totarga tırıştı.
Min anı kotkardım.

Sofia kıçkırıp kölä.
‒ Filip, sin kaharman, äytä.
‒ Közännär kuyannarnı aulıy.
Sin anıñ aşın aldıñ.
Ul siña açulangan, acäp tügel.
Ul töşke aşın aşarga teli.
‒ Niçek sin anı beläseñ? sorıym.

‒ Pış-pış itep tavışladı.
Közän açulanganda şulay tavışlıy ul,
Sofia añlata.
‒ Kuyannı miña kürsätçe. Bik söykemle!
Mañgay çäçe dä bar, dip Sofia äytä dä kölä.
Kinättän küzendä yäşlär.
Kerfeklären sirpep ala.

‒ Sin yugaldıñ, äytä.
‒ Annarı sine yulbarıs belän çitlektä taptım.
Häm dä sineñ belägeñ kanıy.
‒ Yulbarıs! äytäm. ‒ Yulbarısnı onıtkanmın.
Anı kürergä dip äylänäm.
Ul räşätkä yanında yatkan,
avızın açkalap tora.

Karauçı kölä.
‒ Yulbarıs sineñ belän kızıksındı gına, äytä.
‒ Ul inde kart häm dä ayıruça
kurkınıç ta tügel. Alay bulsa da,
yahşı itteñ, aña totınmadıñ.
Ägär dä yulbarıs kurıksa,
kötmägändä kotırınırga mömkin.
‒ Min bit yulbarıska kurkınıç tügel, karşı
kuyam. ‒ Ul minnän küp zurrak.
– Döres, sin aña kurkınıç tügel,
Sofia mıgırdap äytä.
‒ Ämma yulbarıs sinnän kurkırga tiyeş.

# Bülem 27

Ber täbänäk bina yanında
törkem-törkem halık basıp tora.
Anda berniçä karauçı
häm kafe kunakları cıyılgan.
Karauçılarnıñ berse koçagımnan kuyannı ala.
Kuyannıñ tunına kan tamçıları töşkän.

İkençe karauçı keçkenä çitlek kütärgän.
Çitlekkä közänne kertä.
Sofia Ciline kulınnan cibärä dä,
ciñe belän küzen sörtep ala.
Cilineñ kayışın nık tota.
‒ Başmaklarıñda kan, miña äytä.

Apanıñ tavışın işetäm.
Yäşel salam eşläpäsen küräm.
Ul halık arasınnan etep-törtep yanıma kilä.
‒ Filip, şöker isänseñ, Bibinur apa kıçkıra.
‒ Sin nişlädeñ? Tilerdeñme!

Mine kısıp koçaklıy.
Külmäge häm kömeş tösle çantası
kanga buyala, ämma ul anı sizmi.
Eşläpäse cirgä tägäräp töşä.
‒ Filip altınım, apa dävam itä.

– Min bik kaygırdım. Äniyeñ ni äyter inde?
Oy, yärdäm! Huştan kitäm!

Cili ayaklarıma sikerenä.
Min çügälim dä,
anı başınnan sıypap alam.
Ul örä, bitemne yalap ala.
– Akıllı et, mine taptıñ bit, äytäm.

Tege ozın çäçle kız közän yanına yögerä.
Yılagan.
Bitendä yäş ezläre.
– Kitin! Söykemle Kitinem, kız kıçkıra.
– Közänneñ iseme Kitin, karauçı äytä.
Kızınıñ iseme Katarina. Kitin anıkı.
Kitingä daru kadarga yäki veterinarga
kürenergä kiräk vakıtta
Katarina anı haman bire kiterä.

– Kitingä enä kadamakçı idek tä,
ul yugaldı da kuydı.
Bähetebezgä, sin anı taptıñ.
– Közännär azat bulganda,
başka hayvannarga bik küp
zarar kiterä alalar,
ikençe karauçı añlata.
– Kitin mine taptı, çırayımnı sıtıp äytäm.
Bez ber-berebezne yaratmıybız.

# Bülem 28

Sofia ber kulyaulık çıgara da,
belägemdäge kannı sörtep ala.
– Közän niçä tapkır Filipne teşlägän,
karauçıga äytä.
– Belägenä közänneñ teşlävennän
yogışlı mikroblar kerä alamı? Sofia sorıy.

– Yuk. Közänneñ teşläre
bik ütken, karauçı äytä.
– Yaraga bernindi dä bakteriyä kermäs.
Läkin alay bulsa da, Filip,
yarañnı yuarga häm dä
belägeñe bäylärgä kiräk.

– Kuyannı nişlätäsez? tınıçsızlanıp sorıym.
– Közängä birmisezder?
– Tunındagı kannı yuıp alabız da,
anı başka kuyannar yanına iltäbez,
karauçı äytä.
– Ul kaninnar tavında tora.
Bu kuyan bik yış üzenä
yul kazıp annan kaça.
Kaninnar tavınıñ tışkı yagındagı
macaralarnı yarata,
karauçı añlata.

– Min kuyannı öyemä ala alammı?
 sorap karıym.
– Çitlektä totsam,
ul annan kaça almıy.
Monda anardan sezgä barı tik azap kına.

– Äniyeñ kuyannar yaratmıy,
apa süzne bülä.
– Alar öydäge bar närsäne çäynäp beterä.
Kuyannar kabellär yarata.
Komputerıñnıñ kabelen teşläp özä ala.
Minem ber dustımnıñ öy kuyanı bar…

– Biredä kuyan rähaträk yäşi,
karauçı süzne bülä.
– Ul çitlektä yäşärgä künmägän.
Häm dä ul başka kuyannar
belän bergä yäşärgä yarata.
– Kızganıç, äytäm.
– Min bik-bik kuyan telär idem.

Karauçı kuyannı koçagına ala.
Katarina közän çitlegen kütärgän.
Ul bezgä iyärep hayvan karauçılarnıñ
bülmäsenä kerä.

Karauçı yaramnı yua da,
çüpräk belän bäyläp kuya.

Äle inde bik az gına avırta.
Külmägemdäge kannı da
yuarga tırışam.
Sofia miña bulışa.

Közän mine küptapkır teşlägän öçen
Katarina minnän afu sorıy.

– Kitin uynaganda mine dä teşli,
Katarina äytä.
Belägen kürsätä.
Belägendä közänneñ ütken
teşlärennän kalgan
küp ezlär bar.
Annarı Katarina tınıçsızlana.
Mañgayı cıyırıla.
– Et teşlägännän Kitingä
bernindi dä hastalık yokmastır?
dip karauçıdan sorıy.

– Uylamıym. Läkin Kitingä berni
bulmaska ukol kadıy alabız.

Karauçı apama taba borıla.
– Nigä sez hayvan bakçasına
et kiterdegez? karauçı sorıy.
Ul katıgıy tıyılgan.

# Bülem 29

Bibinur apanıñ yöze kızara.
– Bu bit bik bäläkäy, äytä.
– Bili bernindi dä usallık eşlämi.
– Közänne teşläp üterä ala ide, karauçı äytä.
– Pudellar osta auçılar.

Apa tagın da kübräk kızarına.
– Min uyladım… söyli başlıy,
läkin karauçı anıñ süzen bülä:
– Etlär biredäge hayvannarga
kurkınıç hastalıklar kiterä alalar.
Biredäge hayvannarnıñ da etlär
öçen kurkınıç hastalıkları bula ala.
Şunıñ öçen monda etlär
kiterergä yaramıy.
Bezgä hayvannarıbıznı da,
etlärebezne dä epidemiyälärdän
saklarga kiräk.

– Anı min belmädem, apa mıgırdana.
Ber mizgel äkren tora.
Annarı kotı oçıp kıçkıra:
– Bili hastalangan bulsa?
Anı hazer ük veterinarga
kürsätergä kiräk.

– İñ başta Filipneñ belägen hastahanägä
barıp kürsätergä kiräk, karauçı äytä.
– Anıñ belägen yahşı dävalarga kiräk.
Annarı etegez belän veterinarga bara alasız.
– Filipneñ änisenä
şaltıratırga kiräkter, Sofia äytä.
– Min şaltıratam, Bibinur apa äytä.

Apa Ciline tagın çantasına tıga da,
zipperen yaba.
– Äkren utır, Ciligä kisken äytä.
– Siña kotıru avırui yäki
başka kurkınıç hastalık elägergä mömkin.

Apa änigä eşkä şaltırata,
läkin ni bulganın añlatmıy.
Beraz soñlıybız gına, äytä.

Apa eşne akıllı başkardı.
Anıñ öçen rahmät ukıym.
Älegä min änigä barısın da añlatırga telämim.
Minem kanlı kiyemnäremne kürgäç,
älbättä, äni kurkına.
– Äniyeñ sineñ belän söyläşergä teli,
Bibinur apa äytä.
Telefonnı miña suza.
Öç märtäbä yotınam da,
hey dip sälamlıym.

# Bülem 30

Älbttä äni miña açulı.
Hiç tä nervalı tügel. Arıgan gına.
– Filip, tagın azdıñmı?
äni tirän sulap äytä.

– Beraz şulayrak buldı şul.
Bezgä hastahanägä barırga kiräk.
Berni dä bulmaska.
Kurkınıç tügel.
Minem halem yahşı, äytäm.

Äni tagın tirän sulap ala.
– Siña haman ni bulsa bula.
Öygä kaytkaç añlatırsıñ.
Sezne hastahanädän kilep alıymmı?
Yäki ätiyeñä şaltıratıymmı? sorıy.
– Yuk, kiräkmi. Taksi alalabız.
Sau bul! diyäm.

Tagın ni bulsa sorarga ölgermäsen dip
telefonnı tiz genä yabam.

Hastahanägä barganda Sofiaga äytäm:
– Mine kotkarganıñ öçen siña rahmät.
Siña häm Ciligä.

Sin bik batır. Yulbarıstan da kurıkmadıñ.
Hayvannar turında da küp beläseñ.

– Sin dä batır, kuyannı kotkardıñ,
Sofia citdilänep äytä.
– Bolay közän anı aşap kuygan bulır ide.

– Zooparkka tagın
barırga kiräk, Sofiaga äytäm.
– Yulbarısnı häm arıslannı räsemgä
töşerergä ölgermädem.
Läkin ak barsnı şäp räsemgä töşerdem.
– Härhaldä irtägä barmıysız, apa kıçkıra.
– Älegä, miña kalsa,
hayvan bakçası citte.

– İrtägä akvariumga baralabız,
täklif itäm.
– Älbättä, Sofia äytä.
– Beldeñme, yulbarıs akulanıñ teşläre
omere buyı üsä?

– Häm dä ifrat ütkennär, östim.
İkebez dä köläbez.
Sofia kölgändä söykemlegä ohşıy.

– Sez ike ahmak, Bibinur apa äytä.
Huştan kitäm!



**Filip kurkınıç hayvannarnı yarata.**

**Ul hayvan bakçasında öy kuyanınıñ canın kotkara.**

**Filip ber çitlekkä yabılıp kala. Çitlektä bik kurkınıç hayvan tora.**

**Filip annan niçek kotıla?**

ciñel
tel

978-952-7334-36-2

ISBN 978-952-7334-36-2 (Kägaz kitap)
ISBN 978-952-7334-37-9 (E-kitap, PDF)

**aybagar.eu ∘ bokpil.eu**